ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**

от 18.11.2020

г. Казань

**КАРАР**

№ 231-5/э-2020

«Казан дәүләт казна дары заводы» федераль казна предприятиесе һәм «Сетевая компания» ачык акционерлык җәмгыяте челтәр оешмалары арасында үзара исәп-хисап ясау өчен электр энергиясе тапшыру хезмәтләре күрсәтүгә Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 11.12.2019 № 3-1/э карары белән билгеләнгән озак сроклы аерым тарифларга 2021 ел өчен төзәтмә кертү хакында

«Электр энергетикасы турында» 2003 елның 26 мартындагы 35-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Электр энергетикасында җайга салынулы бәяләр (тарифлар) өлкәсендә бәя кую турында» 2011 елның 29 декабрендәге 1178 номерлы карары, Федераль тарифлар хезмәтенең «Ваклап сату (куллану) базарында электр (җылылык) энергиясенә җайга салынулы тарифлар һәм бәяләр исәпләү буенча методик күрсәтмәләр раслау турында» 2004 елның 6 августындагы 20-э/2 номерлы һәм «Электр энергиясе тапшыру буенча хезмәт күрсәтүгә кирәкле тулай табышны озак сроклы индексацияләү алымын кулланып билгеләнә торган тарифларны исәпләү буенча методик күрсәтмәләр раслау хакында» 2012 елның 17 февралендәге 98-э номерлы боерыклары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты турындагы нигезләмә нигезендә, Татарстан Республикасы территориясендәге челтәр оешмалары арасында үзара исәп-хисап ясау өчен электр энергиясе тапшыру буенча хезмәт күрсәтүгә озак сроклы аерым тарифларга һәм җайга салынулы оешмаларның кирәкле тулай табышына 2021 ел өчен төзәтмә кертү максатларында, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының «Казан дәүләт казна дары заводы» федераль казна предприятиесе һәм «Сетевая компания» ачык акционерлык җәмгыяте челтәр оешмалары арасында үзара исәп-хисап ясау өчен электр энергиясе тапшыру хезмәтләре күрсәтүгә 2020-2024 елларга аерым тарифлар билгеләү турында» 11.12.2019 № 3-1/э карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

атамасында «Сетевая компания» ачык акционерлык җәмгыяте тарафыннан» сүзләрен «Сетевая компания» акционерлык җәмгыяте тарафыннан» сүзләренә алмаштырырга;

1 пунктта «Сетевая компания» ачык акционерлык җәмгыяте тарафыннан» сүзләрен «Сетевая компания» акционерлык җәмгыяте тарафыннан» сүзләренә алмаштырырга;

1 нче кушымтаны яңа редакциядә бәян итәргә (кушымтада бирелә);

2 нче кушымтаның 1 пунктында «Сетевая компания» ачык акционерлык җәмгыяте тарафыннан» сүзләрен «Сетевая компания» акционерлык җәмгыяте тарафыннан» сүзләренә алмаштырырга;

3 нче кушымтаны яңа редакциядә бәян итәргә (кушымта итеп бирелә).

2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис А.С.Груничев

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 11.12.2019 № 3-1/э карарына 1 нче кушымта (Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 18.11.2020 № 231-5/э-2020 карары редакциясендә)

2020 елның 1 гыйнварыннан башлап 2024 елның 31 декабренә кадәр Татарстан Республикасы территориясендә «Казан дәүләт казна дары заводы» федераль казна предприятиесе һәм «Сетевая компания» ачык акционерлык җәмгыяте челтәр оешмалары арасында үзара исәп-хисап ясау өчен электр энергиясе тапшыру хезмәтләре күрсәтүгә аерым тарифлар

| Т/с | Челтәр оешмасының исеме | Ел | 1 гыйнвардан 30 июньгә кадәр | | | 1 июльдән 31 декабрьгә кадәр | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | Ике ставкалы тариф | | Бер ставкалы тариф | Ике ставкалы тариф | | Бер ставкалы тариф |
| | | | Электр челтәрләрен карап тоту ставкасы | Технологик чыгым (югалту) өчен түләү ставкасы | | Электр челтәрләрен карап тоту ставкасы | Технологик чыгым (югалту) өчен түләү ставкасы | |
| | | | сум/МВт·ай | сум/МВт·сәг | сум/кВт·сәг | сум/МВт·ай | сум/МВт·сәг | сум/кВт·сәг |
| 1 | «Казан дәүләт казна дары заводы» федераль казна предприятиесе – «Сетевая компания» акционерлык җәмгыяте | 2020 | 131 755,77 | 65,56 | 0,42646 | 131 755,77 | 65,56 | 0,42646 |
| | | 2021 | 87 952,37 | 72,49 | 0,3460 | 87 952,37 | 72,49 | 0,3460 |
| | | 2022 | 137 458,02 | 69,55 | 0,44606 | 137 458,02 | 69,55 | 0,44606 |
| | | 2023 | 140 438,08 | 71,63 | 0,45631 | 140 438,08 | 71,63 | 0,45631 |
| | | 2024 | 143 507,54 | 73,78 | 0,46687 | 143 507,54 | 73,78 | 0,46687 |

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының тариф чишелешләрен кабул итүне оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
11.12.2019 № 3-1/э
карарына 3 нче кушымта
(Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
18.11.2020 № 231-5/э-2020
карары редакциясендә)

2020-2024 елларга «Казан дәүләт казна дары заводы» федераль казна предприятиесенең (югалтуларны исәпкә алмыйча) кирәкле тулаем кереме

| Т/с | Татарстан Республикасындагы челтәр оешмасының исеме | Ел | Югалтуларны исәпкә алмыйча, челтәр оешмасының кирәкле тулай табышы |
|---|---|---|---|
| | | | мең сум |
| 1. | «Казан дәүләт казна дары заводы» федераль казна предприятиесе | 2020 | 2 490,18 |
| | | 2021 | 1 419,55 |
| | | 2022 | 2 597,96 |
| | | 2023 | 2 654,28 |
| | | 2024 | 2 712,29 |

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча
дәүләт комитетының тариф чишелешләрен
кабул итүне оештыру, контрольдә тоту һәм
теркәү бүлеге